Муниципальное бюджетное дошкольное образовательное учреждение

« Детский сад №2» общеразвивающего вида п.г.т.Уруссу

Ютазинского муниципального района Республики Татарстан

Муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе

« 2 нче санлы балалар бакчасы» ш.т.Урыссу бистәсе

Ютазы муниципаль районы Татарстан Республикасы

Каралды һәм кабул ителде:
педагогик совет утырышында
« 29 » август 2022 ел
протокол №1

Раслыйм:
МБМББУ « 2 нче санлы
балалар бакчасы»
ш.т.Урыссу бистәсе мөдире
__________Л.Р.Султанова

Рассмотрено и принято: на
заседании педагогического
совета
от «29 » августа 2022 года
протокол №1

Утверждаю:
заведующая МБДОУ
«Детский сад №2» п.г.т.Уруссу
__________Л.Р.Султанова

# Рабочая программа по обучению детей татарскому языку (4-7 лет)

# Балаларны татар теленә өйрәтү буенча эш программасы (4-7 яшь)

Разработала: воспитатель по
обучению детей татарскому
языку Султанова Л.Р.
Эшләде: балаларны татар теленә
өйрәтү буенча тәрбияче
Солтанова Л.Р.

Уруссу - 2022

## ЭЧТӘЛЕК


| | | |
|---|---|---|
| **I НЧЕ БҮЛЕК. Максатчанлык** | | |
| 1. | **Кереш сүз** | |
| 1.1 | Программаның максаты һәм бурычлары | |
| 1.2 | Программа принциплары | |
| 1.3 | Балаларның яшь үзенчәлекләре | |
| 1.4 | Программа үзләштерүдә көтелгән нәтиҗәләр | |
| **II НЧЕ БҮЛЕК. Эчтәлекле** | | |
| 2.1 | Уртанчылар төркеме (4-5 яшь) | |
| 2.2 | Зурлар төркеме (5-6 яшь) | |
| 2.3 | Мәктәпкә әзерлек төркеме (6-7 яшь) | |
| 2.4 | Эш төрләре һәм формалары | |
| 2.5 | Инновацион  эш | |
| 2.6 | Татар телен үзләштерү дәрәҗәләрен билгеләү, коррекция эше | |
| 2.7 | Ата- аналар белән эш | |
| 2.8 | Педагогик коллектив белән эш | |
| 2.9 | Мәктәп белән бәйләнеш | |
| **III НЧЕ БҮЛЕК. Оештыру** | | |
| 3.1 | Татар телен өйрәтүдә кулланыла торган чаралар | |
| 3.2 | Программаны тормышка ашыру өчен материаль техник шартлар | |
| 3.3 | Әдәбият | |

**Кереш сүз**

Балалар бакчасында рус балаларына татар теле өйрәтү буенча эш программасы (алга таба – Эш программасы) - мәктәпкәчә тәрбия һәм белем учреждениесендә рус һәм башка милләт балаларын татарча сөйләшергә, үзара һәм өлкәннәр белән аралашырга өйрәтү, төрле яктан үсеше өчен мөмкинлекләр тудыруга юнәлтелгән документ булып тора.

Эш программасы Федераль дәүләт белем стандартына (ФГОС) нигезләнеп төзелде, максат һәм бурычларны, көтелгән нәтиҗәләрне, белем бирү процессын оештыруны билгели.

Эш программасы мәктәпкәчә мәгариф системасы эшчәнлеген ачыклаучы норматив -хокукый актлар нигезләмәләренә көйләнгән.

**Федераль җирлегендә:**

- 29.12.2012елдан № 273-ФЗ « Россия Федерациясенең белем бирү турында» Федераль законы;
- Мәктәпкәчә мәгарифнең Федераль дәүләт белем стандарты (Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының 2013елның 17 октябрендә 1155 нче номерлы боерык нигезендә расланган);
- СанПиН 2.4.1.3049-13 « Мәктәпкәчә мәгариф оешмаларының эш шартларын, режимын оештыру буенча санитар-эпидемиологик таләпләр” раслау турында Россия Федерациясе баш дәүләт табибы 2013 ел 15 май 26 нчы номырлы боерыгы;
- “Мәктәпкәчә мәгарифнең белем бирү эшчәнлеген төп гомуми белем бирү программалары нигезендә оештыру һәм тормышка ашыру” (Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының 2013 ел 30 август 1014 нче номерлы боергы);

**Төбәк җирлегендә:**

- Татарстан Республикасының 2013ел 22 июль 68-ЗРТ номерлы «Белем бирү турында» Законы;
- Татарстан Республикасының “Татарстан Республикасында Татарстан Республикасының дәүләт телләре һәм башка телләр турында” Законы;

**Мәктәпкәчә белем учреждениесе җирлегендә:**

- МАМББУ Уставы;
- МАМББУнең төп белем бирү программасы турында нигезләмәсе;

Эш программасы өч бүлектән (максатчанлык, эчтәлекле, оештыру) тора, белем бирү өлкәләре буенча куелган бурычларны күздә тота.

**I НЧЕ БҮЛЕК. Максатчанлык**

**Программаның максаты:**

Информацион – коммуникатив технологияләр, уен – ситуацияләр, күргәзмәлелек кулланып, тел өйрәтү, аралашу теләге тудыру.

**Бурычлар:** 1. Балаларның көнкүрешкә, табигатькә, җәмгыятькә кагылышлы сүзләр исәбенә сөйләмнәрен баету, сүз һәм сүзтезмәләрне төрле ситуацияләрдә кулланышка кертү.

2. Мөстәкыйль фикер йөртергә, җавап бирергә күнектерү, балада үзенең сөйләме белән кызыксыну һәм сизгерлек уяту.

3. Диалогик һәм монологик сөйләмне, хәтер, зиһен сәләтләрен үстерү.

4. Сөйләм әдәбе (сорау, гозер, мөрәҗәгать итү, рәхмәт белдерү, исәнләшү, саубуллашу) кагыйдәләрен, бер – береңне тыңлау, ишетү сыйфатлары, әдәпле итеп кара-каршы сөйләшә белү күнекмәләрен тәрбияләү.

**Вступительное слово**

Программа разработана в соответствие с ФГОС к структуре основной образовательной программе по обучению детей татарскому языку(УМК), а также в соответствие с культурно - историческими подходами к проблеме обучения детей татарскому языку . Программа обеспечивает осуществление образовательного процесса, который включает совместную деятельность взрослого и ребенка, самостоятельную деятельность детей. Программа направлена на развитие речи детей посредством приобщения к истокам национальной культуры, изучения татарского языка. В программе отражено содержание образования детей от 3 до 7 лет.

Рабочая программа основана на нормативно-правовых актах, определяющие работу системы дошкольного образования.

На Федеральном уровне:

- Федеральный закон № 273-ФЗ от 29.12.2012г. « Россия Федерациясенең белем бирү турында»;
- ФГОС дошкольного образования (утвержден приказом Министерства образования и науки РФ №1155 от 17.10.2013г.);
- СанПиН 2.4.1.3049-13 «Мәктәпкәчә мәгариф оешмаларының эш шартларын, режимын оештыру буенча санитар-эпидемиологик таләпләр” приказ главного государственного врача РФ №26 от 15.05.2013г.;
- “Мәктәпкәчә мәгарифнең белем бирү эшчәнлеген төп гомуми белем бирү программалары нигезендә оештыру һәм тормышка ашыру” (приказ Министерства образования и науки РФ №1114 от 30.08.2013г.);

**На региональном уровне:**

- Закон РТ №68-ЗРТ от 22.07.2013г. “Об образовании”;
- Закон РТ “Татарстан Республикасында Татарстан Республикасының дәүләт телләре һәм башка телләр турында”;

**На уровне дошкольного образовательного учреждения:**

- Устав МБДОУ;
- Основная образовательная программа МБДОУ;

**Цель:** Ознакомление с татарским языком как средством общения, с культурой татарского народа через информационно-коммуникативные технологии, игровые ситуации, наглядные материалы.

**Задачи:**

1. Научить понимать татарскую речь на слух, говорить по-татарски в пределах доступной тематики усвоенных слов, грамматических конструкций и форм.
2. Формировать и развивать первоначальные умения и навыки практического владения татарским языком в устной форме.
3. Расширить представление детей об образе жизни татарского народа, их обычаях, традициях, фольклоре.
4. Воспитывать интерес изучению языка.

**Программа үзләштерүдә көтелгән нәтиҗәләр**

**Уртанчылар төркеме (4-5 яшь)**
**“Минем өем” проекты**

**Белем бирү эшчәнлегенең бурычлары**

1.Тирә- юнь күзаллавын киңәйтә барып, иң якын кешеләре, уенчыклар, ашамлыклархисабына сүз байлыгын арттыру.
2.Өлкәннәр кушкан катлаулы булмаган биремнәрне аңлап, үти белүләренә ирешү.
3.Тәрбияче әйткән сүзләрне, кыска фразаларны кабатлап әйтә белүләренә ирешү.
4.Үз исемен дөрес әйтә, исәнләшә, саубуллаша, рәхмәт әйтә белү күнекмәләрен үстерү.
5.Куелган сорауларны аңлап, сөйләмдә 2-3 сүз белән җавап кайтару күнекмәләрен үстерү.

**Белем бирү эшчәнлегенең эчтәлеге**

**Лексик минимум** – якынча 62 сүз.
“Минем өем” проекты темалары (“Гаилә”,“Ашамлыклар”,“Уенчыклар”,“Саннар”) буенча бирелгән лексиканы төрле ситуацияләрдә ишетеп аңлап куллана белергә өйрәтү, сөйләм күнекмәләрен булдыру.
Аларның тирә-юнь күзаллавын киңәйтә бару, югарыда күрсәтелгән темага караган сүзләр хисабына балаларның сүз байлыгын арттыру өстендә эшләү, аларда татар телендә сөйләшә башлау теләге уяту.
Актив үзләштерүләренә ирешү өчен әйбер исемнәренең мәгънәсен аңлату һәм аларны дөрес әйтү күнегүләре эшләү. Иң якын кешеләр (*әти, әни, бабай, әби, малай, кыз)*, яраткан уенчыклар (*туп, машина, курчак, эт, песи куян, аю),* ашамлыклар *(алма, ипи, сөт, чәй)* һәм саннар *(бер, ике, өч, дүрт, биш)* хисабына сүзлекне баету һәм активлаштыру. Өйрәнгән сүзләрне аерым, күмәк, тәрбияче ярдәмендә кабатлый белү күнекмәләрен булдыру. *Алма бир. Мә, алма*.
Бу кем? Бу нәрсә? сорауларын аңлап җавап бирергә өйрәтү.
-*Бу кем? – Бу әти.*
-*Бу нәрсә? – Бу туп.*
Нинди? соравын аңларга, дөрес җавап бирергә өйрәтү.
-*Туп нинди? – Кечкенә.*
-*Машина нинди? – Матур.*
Әйбернең билгесен ачыклау максаты белән куела торган сорауларны аңларга һәм сөйләмдә җавап кайтарырга өйрәтү. (Зур, матур, кечкенә, чиста, әйбәт, пычрак, тәмле).
-*Бу нәрсә? – Бу туп.*
-*Туп нинди? – Туп пычрак (зур, матур, кечкенә, чиста, әйбәт).*
Тәрбияче әйткән сүзләрне, кыска фразаларны балаларның кабатлап әйтә белүләренә ирешү өстендә эшләү. Аларның өлкәннәр кушкан катлаулы булмаган биремнәрне аңлап, үти белүләренә ирешү *(мә, бир, утыр, аша, эч, уйна, ю, ал).*
-*Мә, куян. – Бир куян.*

Тәрбияче әйткән билге буенча предметны табу, күрсәтә белергә өйрәтү.
*Зур машина ал. Тәмле алма бир.*
Үз исемен дөрес әйтә, исәнләшә, саубуллаша белергә өйрәтү, сүзләрне дөрес, урынлы куллану.
*Исәнме. – Исәнмесез. Сау бул. – Сау булыгыз. Мин кыз. - Мин Оля. Мин малай - Мин Коля.*
Таныш предметларның исемнәрен ныгыту, куелган сорауга раслаучы, инкарь итүче сүзләрне *(әйе, юк)* дөрес кулланырга өйрәтү
*Син Коля? – Әйе.*
*Син кыз? – Юк, мин малай.*
Мин, син алмашлыкларын аңларга һәм урынлы кулланырга өйрәтү.
*Син кем? – Мин Коля.*
Кечкенә күләмле шигырьләр, җырлар өйрәтү.

**Белем бирү эшчәнлегенең нәтиҗәләре**

**Ирешелгән нәтиҗәләр:**

Өлкәннәр кушкан катлаулы булмаган биремнәрне аңлап, үти белә.
Тәрбияче әйткән сүзләрне, кыска фразаларны кабатлап әйтә белә.
Үз исемен дөрес әйтә, исәнләшә, саубуллаша, рәхмәт әйтә белә.
Куелган сорауларны аңлап, сөйләмдә 2-3 сүз белән җавап кайтара белә.
Бер-берсе һәм өлкәннәр белән 62 сүз кулланып татар телендә аралаша.
Бирелгән лексиканы төрле ситуацияләрдә ишетеп аңлап куллана белә, сөйләм күнекмәләре бар.
Татар телендә сөйләшү теләге бар.
Әйбер исемнәренең мәгънәсен аңлый һәм аларны дөрес әйтә белә.
Гаилә, уенчыклар, ашамлыклар һәм саннар хисабына сүз байлыгы бар.
Өйрәнгән сүзләрне аерым, күмәк, тәрбияче ярдәмендә кабатлый белә.
Бу кем? Бу нәрсә? сорауларын аңлап, җавап бирә.
Әйбернең билгесен ачыклау максаты белән куела торган сорауны аңлый һәм сөйләмдә җавап кайтара белә.
Тәрбияче әйткән сүзләрне, кыска фразаларны кабатлап әйтә. Өлкәннәр кушкан катлаулы булмаган биремнәрне аңлап үти.
Тәрбияче әйткән билге буенча предметны таба, күрсәтә белә.
Үз исемен дөрес әйтә, исәнләшә, саубуллаша белә, сүзләрне дөрес, урынлы куллана.
Куелган сорауга раслаучы, инкарь итүче сүзләрне дөрес кулланана белә.
Мин, син алмашлыкларын аңлый һәм урынлы куллана.
Кечкенә күләмле шигырьләр, җырлар белә.

**Тәрбияче һәм ата- аналар белән берлектә ирешергә кирәк нәтиҗәләр:**

Сүз байлыгы аз.
Бирелгән лексиканы ишетеп аңлый, куллана белми.
Сорауларны аңлый, җавап бирә алмый.
Мин, син алмашлыкларын урынлы куллана белми.

**Зурлар төркеме (5-6 яшь)**
**“Уйный – уйный үсәбез” проекты**

**Белем бирү эшчәнлегенең бурычлары**

1. Тирә- юнь күзаллавын киңәйтә барып, яшелчәләр, савыт-сабалар, киемнәр, өй җиһазлары, ашамлыклар темасына кергән сүзләр хисабына сүз байлыгын арттыру.
2. Гади сорауларны аңлап җавап бирү, мөрәҗәгать итә белүләренә ирешү.
3. Үзара һәм зурлар белән көндәлек тормышта татарча аралашуга чыгуларына ирешү.
4. Сөйләм күнекмәләрен үстерешле диалогларда, уеннарда, ситуатив күнегүләрдә камилләштерү.
5. Боерык фигыльләрне сөйләмдә аңлап дөрес куллана белү күнекмәләрен үстерү.

**Белем бирү эшчәнлегенең эчтәлеге**

**Лексик минимум** – якынча 45 сүз.
“Уйный-уйный үсәбез” проекты темалары (“Гаилә”, “Ашамлыклар”, “Уенчыклар”, “Саннар” **, “**Яшелчәләр”, “Савыт-саба”, “Киемнәр”, “Шәхси гигиена”, “Өй җиһазлары”, “Бәйрәмнәр”) буенча бирелгән лексиканы төрле эшчәнлектә (уен, аралашу, музыка, хезмәт, хәрәкәт) ишетеп аңлап куллана белергә өйрәтү, сөйләм күнекмәләрен булдыру.
Яңа сүзләр хисабына баланың сөйләмен баету, тулыландыру. (*Кишер, суган, бәрәңге, кыяр, кәбестә, аш, ботка, кашык, тәлинкә,чынаяк, күлмәк, чалбар, бит, кул, өстәл урындык, карават, баллы, ничә, нинди, алты, җиде, сигез, тугыз, ун, кызыл, сары, яшел, зәңгәр, нәрсә кирәк, юа, ки, сал, йокла, хәерле көн, яратам, бар).*
Санау күнекмәләрен ныгыту, сөйләмдә камилләштерү.
Нәрсә кирәк? Нинди? Ничә? соравын аңлап, мөстәкыйль рәвештә сорау куя һәм дөрес җавап бирә белергә өйрәтү.
Раслаучы һәм инкарь итүче сүзләрне ныгыту, урынлы куллану. *(Әйе, юк)*
Исем + сыйфат конструкциясен сөйләмдә активлаштыру.
- *Бу кызыл тәлинкә.*
“Минем өем” проекты буенча өйрәнелгән боерык фигыльләрне ныгыту *(аша, эч, утыр, ю, уйна, йокла)*, яңа боерык фигыльләрне *(ки, сал)* сөйләмдә аңлап дөрес куллана белергә өйрәтү, активлаштыру.
Алган белемнәрен, сөйләм күнекмәләрен үстерешле диалогларда, уеннарда, ситуатив күнегүләрдә камилләштерү.

**Белем бирү эшчәнлегенең нәтиҗәләре**

**Ирешелгән нәтиҗәләр:**
Гади сорауларны аңлап җавап бирү, мөрәҗәгать итә белә.
Үзара һәм зурлар белән көндәлек тормышта107 сүз кулланып татар телендә аралаша.
Сөйләм күнекмәләрен үстерешле диалогларда, уеннарда, ситуатив күнегүләрдә

куллана.
Боерык фигыльләрне сөйләмдә аңлап, дөрес куллана.
“Уйный-уйный үсәбез” проекты темалары ( “Гаилә”, “Ашамлыклар”, “Уенчыклар”, “Саннар” , “Яшелчәләр”, “Савыт-саба”, “Киемнәр”, “Шәхси гигиена”, “Өй җиһазлары”, “Бәйрәмнәр”) буенча бирелгән лексиканы төрле эшчәнлектә (уен, аралашу, музыка, хезмәт, хәрәкәт) ишетеп аңлап куллана белә, сөйләм күнекмәләре бар.
Яңа сүзләр хисабына сүз байлыгы бар.
Санау күнекмәләре бар, сөйләмдә куллана белә.
Нәрсә кирәк? Нинди? Ничә? соравын аңлап, мөстәкыйль рәвештә сорау куя һәм дөрес җавап бирә.
Раслаучы һәм инкарь итүче сүзләрне аңлый, урынлы куллана.
Исем + сыйфат конструкциясен сөйләмдә дөрес куллана.
Боерык фигыльләрне сөйләмдә аңлап дөрес куллана белә.
Алган белемнәрен, сөйләм күнекмәләрен үстерешле диалогларда, уеннарда, ситуатив күнегүләрдә куллана белә.

**Тәрбияче һәм ата- аналар белән берлектә ирешергә кирәк нәтиҗәләр:**
Сүз байлыгы аз.
Бирелгән лексиканы ишетеп аңлый, куллана белми.
Сорауларны аңлый, мөстәкыйль рәвештә сорау куя белми.
Сөйләм күнекмәләрен үстерешле диалогларда, уеннарда, ситуатив күнегүләрдә куллана алмый.

## Мәктәпкә әзерлек төркеме (6-7 яшь)
## “Без инде хәзер зурлар – мәктәпкә илтә юллар”проекты

### Белем бирү эшчәнлегенең бурычлары

1. Ашамлыклар, кыргый хайваннар, кошлар, мәктәп темасына кергән сүзләр хисабына баланың сөйләмен баету, тулыландыру.
2. Сөйләмне аралашу чарасы буларак камилләштерү, файдалана белү күнекмәләренә өйрәтү.
3. Диалогик һәм монологик сөйләмне үстерү.
4. Мөстәкыйль рәвештә сорау куя һәм дөрес җавап бирә белергә күнектерү.

### Белем бирү эшчәнлегенең эчтәлеге

**Лексик минимум** – якынча 60 сүз.
“Без инде хәзер зурлар – мәктәпкә илтә юллар” проекты темалары ( “Гаилә”, “Ашамлыклар”, “Уенчыклар”, “Саннар” , “Яшелчәләр”, “Савыт-саба”, “Киемнәр”, “Шәхси гигиена”, “Өй җиһазлары”, “Бәйрәмнәр”, “Танышу”, “Тату гаилә”, “Дусларны сыйлыйбыз”, “Кунак килде”, “Кафега барабыз”, “Күңелле уеннар”, “Без циркта”, “Безнең дуслар”, “Чана шуабыз”, “Без биибез”, “Күңелле сәяхәт”, “Мәктәп”, “Без әкият яратабыз”) буенча бирелгән лексиканы төрле эшчәнлектә (танып – белү, уен, аралашу, музыка, хезмәт, хәрәкәт) ишетеп аңлап куллана белергә өйрәтү, сөйләм күнекмәләрен булдыру.

Яңа сүзләр хисабына баланың сөйләмен баету, тулыландыру: *син кем, хәерле көн, тычкан, бу кем, бу нәрсә, нишли, йоклый, утыра, ашый, эчә, нишлисең, ашыйм, эчәм, уйный, уйныйм, утырам, барам, кая барасың, син нишлисең, сикер-сикерәм, сикерә, йөгерә, төлке, йөгер-йөгерәм, чәк-чәк, өчпочмак, яшь, бүре, керпе, тавык, әтәч, үрдәк, чана, шуа, шуам, бие, бии, биим, ак, кара, җырла-җырлыйм, зур рәхмәт, китап укый, рәсем ясыйм, укыйм, дәфтәр.*

Бу кем? Бу нәрсә? Нәрсә кирәк? Нинди? Ничә? Нишли? Син нишлисең? Кая барасың? соравын аңлап, мөстәкыйль рәвештә сорау куя һәм дөрес җавап бирә белергә өйрәтү.

Алган белемнәрен, сөйләм күнекмәләрен үстерешле диалогларда, уеннарда, ситуатив күнегүләрдә камилләштерү. Монологик сөйләмне үстерү.

**Белем бирү эшчәнлеге нәтиҗәләре**

**Ирешелгән нәтиҗәләр:**

Сөйләмне аралашу чарасы буларак файдалана белә.

Диалогик һәм монологик сөйләм күнекмәләре бар.

Мөстәкыйль рәвештә сорау куя һәм дөрес җавап бирә белә.

Бер-берсе һәм өлкәннәр белән 167 сүз кулланып татар телендә актив аралаша.

“Без инде хәзер зурлар – мәктәпкә илтә юллар” проекты темалары ( “Гаилә”, “Ашамлыклар”, “Уенчыклар”, “Саннар” **, “**Яшелчәләр”, “Савыт-саба”, “Киемнәр”, “Шәхси гигиена”, “Өй җиһазлары”, “Бәйрәмнәр”, “Танышу”, “Тату гаилә”, “Дусларны сыйлыйбыз”, “Кунак килде”, “Кафега барабыз”, “Күңелле уеннар”, “Без циркта”, “Безнең дуслар”, “Чана шуабыз”, “Без биибез”, “Күңелле сәяхәт”, “Мәктәп”, “Без әкият ятабыз”) буенча бирелгән лексиканы төрле эшчәнлектә (танып – белү, уен, аралашу, музыка, хезмәт, хәрәкәт) ишетеп аңлап куллана белә, сөйләм күнекмәләрен бар.

Яңа сүзләр хисабына сүз байлыгы бар.

Бу кем? Бу нәрсә? Нәрсә кирәк? Нинди? Ничә? Нишли? Син нишлисең? Кая барасың? соравын аңлап, мөстәкыйль рәвештә сорау куя һәм дөрес җавап бирә белә.

Фигыльләрне урынлы куллана.

Җырлар, шигырьләр белә.

**Тәрбияче һәм ата- аналар белән берлектә ирешергә кирәк нәтиҗәләр:**

Яңа сүзләр хисабына сүз байлыгы аз.

Бирелгән лексиканы диалогик һәм монологик сөйләмдә куллана алмый.

“Бу кем?”, “Бу нәрсә?”, “Нәрсә кирәк?”, “Нинди?”, “Ничә?”, “Нишли?”, “Син нишлисең?” “Кая барасың?” сорауларын мөстәкыйль рәвештә куя белми. Фигыльләрне урынлы куллана белми.

**2НЧЕ БҮЛЕК.** Эчтәлек

## УРТАНЧЫЛАР ТӨРКЕМЕ «МИНЕМ ӨЕМ» ПРОЕКТЫ БУЕНЧА ТЕМАТИК ПЛАН

| АКТИВ СҮЗЛӘР | СӨЙЛӘМ ҮРНӘГЕ | АУДИОЯЗМА<br>ЭШ ДӘФТӘРЕ<br>АНИМАЦИОН СЮЖЕТ |
|---|---|---|
| **ГАИЛӘ – 18 СӘГАТЬ (1-18)** | | |
| әти<br>әни | -Бу кем?<br>-Әти (әни, бабай, әби, кыз, малай). | Аудиоязма №1-23 |
| малай<br>кыз | -Кем юк?<br>-Әти (әни, бабай, әби, малай, кыз). | Сюжетлар:<br>1. “Әйдәгез, дуслашыйк”<br>2. “Качышлы уйныйбыз”<br>3. “Шалкан” |
| мин<br>исәнмесез<br>сау булыгыз | -Исәнмесез.<br>-Син кем?<br>-Мин Коля (Оля).<br>-Мин малай.<br>-Сау булыгыз! | |
| исәнме | -Исәнме, әни (әти, бабай, әби, кыз, малай, Мияу, Акбай).<br>-Сау бул, әни (әти, бабай, әби, кыз, малай). | |
| <br><br>эт<br>песи | -Кем анда?<br>-Мин песи. Мин Мияу.<br>-Кил монда.<br>-Мин эт. Мин Акбай.<br>-Кил монда.<br>-Син Коля?<br>-Әйе, Коля.<br>-Син малай (кыз)?<br>-Әйе (юк). | |
| әйе<br>юк | | |
| сау бул | -Әти? (әни, бабай, әби, кыз, малай).<br>-Әйе. | |

| | | |
|---|---|---|
| әби<br>бабай<br><br><br><br><br><br>әйбәт | -Әни? (әти, бабай, әби, кыз, малай).<br>-Юк.<br><br>-Малай?<br>-Юк, кыз.<br>-Кыз?<br>-Әйе, кыз.<br><br>-Хәлләр ничек?<br>-Әйбәт. | |
| **АШАМЛЫКЛАР – 12 СӘГАТЬ (19-30)** | | |
| ипи<br><br>алма<br>сөт<br>чәй<br><br>мә<br>рәхмәт<br><br>тәмле<br>кил монда<br><br>утыр<br><br>аша<br>эч | -Мә, ипи (алма, сөт, чәй).<br>-Рәхмәт, әби.<br><br>-Коля, мә ипи (алма, сөт, чәй).<br>-Рәхмәт.<br><br>-Мияу, кил монда. Утыр. (Акбай, Коля, Оля)<br><br>-Оля, кил монда. Мә ипи (алма, сөт, чәй). Ипи (алма, сөт, чәй) тәмле (ме)?<br>-Ипи (алма, сөт, чәй) тәмле. Рәхмәт.<br><br>-Мә, тәмле алма (ипи).<br><br>-Мә, ипи (алма) аша.<br>-Мә, сөт (чәй) эч. | Аудиоязма №24-39<br><br>Сюжетлар:<br>1.“Тәмле” кибетендә”<br>2. “Азат кунак чакыра” |
| **УЕНЧЫКЛАР – 18 СӘГАТЬ (31-48)** | | |
| бир<br>туп<br><br>зур<br>кечкенә<br><br>матур<br>курчак | - Бу нәрсә?<br>- Туп (курчак, куян, аю).<br><br>-Курчак (туп, куян, аю) бир.<br>-Мә, курчак (туп, куян, аю).<br><br>-Бу нәрсә?<br>-Аю (курчак, куян, туп).<br>-Аю (курчак, куян, туп) нинди? | Аудиоязма №40-53<br><br>Сюжетлар:<br>1. “Паркка сәяхәт”<br>2. “Уенчыклар үпкәләгән”<br>3. “Күңелле уеннар”<br>4. “Акбай һәм Мияу мажаралары” |

| | | |
|---|---|---|
| куян<br>аю<br><br><br><br><br><br><br><br><br><br><br><br><br><br><br><br><br><br><br><br><br><br><br><br>хәлләр ничек?<br><br>уйна<br><br>пычрак<br>чиста<br><br>ю | -Аю (курчак, куян, туп) зур (матур, кечкенә, әйбәт).<br><br>- Аю (курчак, куян, туп) нинди?<br>- Аю (курчак, куян, туп) зур (кечкенә, матур, әйбәт).<br><br>-Аю (курчак, куян, туп)?<br>-Әйе.<br>-Курчак (аю, куян, туп)?<br>-Юк.<br><br>-Бу нәрсә?<br>-Аю (курчак, куян, туп).<br>-Мә, аю (курчак, куян, туп). Уйна.<br><br>-Коля, кил монда. Уйна.<br>-Оля, кил монда. Уйна.<br><br>- Аю (курчак, куян, туп) бир.<br>- Аю (курчак, куян, туп) нинди?<br>- Аю (курчак, куян, туп) зур.<br>- Аю (курчак, куян, туп) кечкенә.<br><br>- Мә, зур аю (курчак, куян, туп).<br>- Мә, кечкенә аю (курчак, куян, туп).<br>-Аю (курчак, куян), кил монда. Аша (утыр, эч, уйна).<br><br>-Коля (Оля), аю (курчак, куян, туп) ю.<br><br>-Туп (курчак, куян, аю) нинди?<br>-Туп (курчак, куян, аю) пычрак (чиста).<br>-Туп ю.<br>- Туп чиста?<br>- Юк, туп пычрак.<br>(Әйе, туп чиста).<br>Ю, ю, ю – туп (курчак, аю, куян) ю. | |
| **САННАР - 6 СӘГАТЬ (49-54)** | | |

| | | |
|---|---|---|
| бер<br>ике<br>өч<br>дүрт<br>биш | -Ничә?<br>-Бер (ике, өч, дүрт, биш) алма.<br><br>-Ничә малай?<br>-Бер (ике, өч, дүрт, биш) малай.<br>-Ничә кыз?<br>-Бер (ике, өч, дүрт, биш) кыз.<br><br>-Өч?<br>-Юк.<br>-Ике?<br>-Әйе.<br><br>-Ничә аю (туп, курчак, куян)?<br>-Бер (ике, өч, дүрт, биш) аю. | Аудиоязма №54-60<br>Сюжет:<br>1.“Уйный-уйный саныйбыз” |
| | **КАБАТЛАУ - 6 СӘГАТЬ (55-60)** | |
| | | Аудиоязма №61-64<br>Сюжет: “Күңелле ял итәбез” |

**ЗУРЛАР ТӨРКЕМЕ**
**«УЙНЫЙ-УЙНЫЙ ҮСӘБЕЗ» ПРОЕКТЫ БУЕНЧА ТЕМАТИК ПЛАН**

| **АКТИВ СҮЗЛӘР** | **СӨЙЛӘМ ҮРНӘГЕ** | **АУДИОЯЗМА**<br>**ЭШ ДӘФТӘРЕ**<br>**АНИМАЦИОН СЮЖЕТ** |
|---|---|---|
| | **КАБАТЛАУ – 3 СӘГАТЬ (1-3)** | |
| | “Минем өем” проекты буенча | Аудиоязма №1<br>Сюжет:<br>1. “Шалкан” |
| | **ЯШЕЛЧӘЛӘР – 21 СӘГАТЬ (4-24)** | |

| | | |
|---|---|---|
| кишер<br><br><br><br>баллы<br><br>ничә<br><br>суган<br>бәрәңге<br><br>кыяр<br><br>кәбестә<br>нинди<br><br>алты<br>җиде<br>сигез<br>тугыз<br>ун | -Бу нәрсә?<br>-Кишер.<br>-Мә, кишер.<br><br>-Нинди кишер (суган, бәрәңге, кәбестә, кыяр)?<br>-Зур (кечкенә) кишер (суган, бәрәңге, кәбестә, кыяр)<br>-Мә, зур (кечкенә) кишер (суган, бәрәңге, кәбестә, кыяр)<br>-Рәхмәт.<br><br>-Зур кишер (суган, бәрәңге, кәбестә, кыяр)<br>-Кечкенә кишер (суган, бәрәңге, кәбестә, кыяр)<br>-Чиста кишер (суган, бәрәңге, кәбестә, кыяр)<br>-Пычрак кишер (суган, бәрәңге, кәбестә, кыяр)<br><br>-Кишер (суган, бәрәңге, кәбестә, кыяр) нинди?<br>-Кишер (суган, бәрәңге, кәбестә, кыяр) тәмле, зур (кечкенә), матур, чиста (пычрак)<br><br>Кишер баллы.<br>Алма баллы.<br>-Мә кишер(алма), аша. Баллы?<br>-Әйе, баллы. Рәхмәт.<br><br>-Ничә кишер (суган, бәрәңге, кәбестә, кыяр)? Сана.<br>-Ике (1-10) кишер (суган, бәрәңге, кәбестә, кыяр)<br>-Оля, кил монда. Мә, ике (1-10) кишер (суган, бәрәңге, кәбестә, кыяр)<br>-Ике (1-10) кишер (суган, бәрәңге, кәбестә, кыяр)<br><br>-Оля, кыяр (суган, бәрәңге, кәбестә, кишер) бир.<br>-Мә, кыяр (суган, бәрәңге, кәбестә,кишер).<br>-Рәхмәт.<br><br>-Коля, (1-10) кәбестә (суган, бәрәңге, кишер, кыяр) бир.<br>-Мә, (1-10) кәбестә (суган, бәрәңге, кишер, кыяр).<br>-Сау бул, Коля. | Аудиоязма №2-24<br><br>Сюжетлар:<br>1.“Баллы кишер”<br>2. “Уйный-уйный эшлибез”<br>3. “Юл маҗаралары”<br>4. “Кем эшләми, шул ашамый” |

<table>
<tr><td>кызыл<br>сары<br><br><br>яшел<br><br><br><br><br>нәрсә кирәк?<br><br><br><br><br>юа</td><td>-Ничә кыяр (суган, бәрәңге, кәбестә, кишер)?<br>-Бер (1-10) кыяр (суган, бәрәңге, кәбестә, кишер).<br>-Кыяр (суган, бәрәңге, кәбестә, кишер) пычрак.<br><br>-Бу туп.<br>-Туп (алма) нинди?<br>-Туп (алма) сары (кызыл, яшел)<br><br>-Нинди туп (алма) юк?<br>-Кызыл (сары, яшел) туп (алма) юк.<br><br>-Кишер (суган, бәрәңге, кәбестә, кыяр) кирәк?<br>-Кирәк.<br><br>-Коля, нәрсә кирәк?<br>-Кыяр (суган, кишер, бәрәңге, кәбестә) кирәк.<br>-Нинди кыяр?<br>-Яшел (тәмле, чиста) кыяр.<br><br>-Кыяр (суган, кишер, бәрәңге, кәбестә) пычрак.<br>-Мә, кыяр (суган, кишер, бәрәңге, кәбестә) ю.<br>-Оля кыяр ( суган, кишер, бәрәңге, кәбестә) юа.</td><td></td></tr>
<tr><td colspan="3">АШАМЛЫКЛАР – 6 СӘГАТЬ (25-30)</td></tr>
<tr><td>аш<br>ботка</td><td>тәмле аш (ботка, сөт, ипи, чәй)<br><br>-Нәрсә кирәк?<br>-Аш (ботка, сөт, ипи, чәй, кишер, кәбестә, кыяр, бәрәңге) кирәк.<br>-Нинди аш (ботка, сөт, ипи, чәй, кишер, кәбестә, кыяр, бәрәңге)?<br>-Тәмле аш (ботка, сөт, ипи, чәй, кишер, кәбестә, кыяр, бәрәңге).<br>-Мә, аш (ботка, сөт, ипи, чәй, кишер, кәбестә, кыяр, бәрәңге) аша (эч).<br>-Рәхмәт. Аш (ботка, сөт, ипи, чәй, кишер, кәбестә, кыяр, бәрәңге) тәмле.</td><td>Аудиоязма №25-29<br><br>Сюжет:<br>1.“Аш бүлмәсе”</td></tr>
<tr><td colspan="3">САВЫТ-САБА - 6 СӘГАТЬ (31-36)</td></tr>
</table>

| | | |
|---|---|---|
| кашык<br>тәлинкә<br><br>чынаяк<br><br>зәңгәр | -Кашык (тәлинкә, чынаяк) бир.<br>-Нинди кашык (тәлинкә, чынаяк)?<br>-Зур (кечкенә, сары, яшел, кызыл, зәңгәр).<br>-Ничә кашык (тәлинкә, чынаяк)?<br>-(1-10 га) кашык (тәлинкә, чынаяк).<br>-Мә, (1-10) кашык(тәлинкә, чынаяк).<br>-Мә, кызыл (сары, яшел, зәңгәр). чынаяк (тәлинкә, чынаяк). | Аудиоязма №30-37<br>Сюжет:<br>1. “Өч аю”<br>2. “Чисталыкта - матурлык” |
| **КИЕМНӘР - 6 СӘГАТЬ (37-42)** | | |
| күлмәк<br><br>чалбар<br><br><br><br><br><br><br><br><br><br><br>ки<br><br><br><br>сал<br><br>йокла | яшел (кызыл, сары, зәңгәр) күлмәк (чалбар).<br><br>чиста күлмәк (чалбар).<br>матур күлмәк (чалбар).<br><br>күлмәк (чалбар) юк.<br><br>-Оля, күлмәк (чалбар) бир.<br>-Нинди күлмәк (чалбар)?<br>-Сары (кызыл, яшел, зәңгәр) күлмәк (чалбар).<br>-Ничә күлмәк (чалбар)?<br>-Бер (1-10) күлмәк (чалбар).<br><br>-Курчак, чалбар (күлмәк) ки (сал).<br><br>-Оля, чалбар (күлмәк) бир.<br>-Мә, чалбар (күлмәк).<br>-Рәхмәт. Курчак, мә, чалбар (күлмәк) ки (сал).<br><br>-Курчак, йокла. | Аудиоязма №38-43<br><br><br>Сюжет:<br>1.“Киемнәр кибетендә”<br>2.“Шаян уенчыклар” |
| **ШӘХСИ ГИГИЕНА – 3 СӘГАТЬ (43-45)** | | |
| бит<br>кул<br>хәерле көн | -Хәерле көн.<br>-Мә су, бит (кул) ю.<br><br>-Бит (кул) чиста.<br><br>-Бит (кул) чиста.<br>-Әйе, бит (кул) чиста. | Аудиоязма № 43, 44-48<br><br><br>Сюжет:<br>1.“Ни өчен киемнәр югалган?” |

| ӨЙ ҖИҺАЗЛАРЫ – 3 СӘГАТЬ (46-48) | | |
|---|---|---|
| өстәл<br>урындык<br>карават | -Зур (кечкенә) урындык (өстәл, карават).<br><br>-Зур аю, мә зур карават (өстәл, урындык).<br>-Кечкенә аю, мә кечкенә карават (өстәл, урындык).<br><br>-Нәрсә кирәк?<br>-Карават (өстәл, урындык) кирәк.<br>-Нинди карават?<br>-Зур (кечкенә, сары, яшел, зәңгәр) карават.<br>-Мә, зур карават.<br>-Рәхмәт. | Аудиоязма № 49<br><br><br>Сюжет:<br>1.“Маша һәм өч аю” |
| **БӘЙРӘМ “ТУГАН КӨН” – 9 СӘГАТЬ (49-57)** | | |
| яратам<br><br><br><br><br><br><br><br><br>бар | -Мин алма (ипи, сөт, чәй, ботка, аш, кыяр, кәбестә, бәрәңге, кишер) яратам.<br><br>-Мин Коля(ны) (Оля(ны) яратам.<br><br>-Мин курчак(ны) (аю(ны), песи(не), эт(не), куян(ны) яратам.<br><br>-Нәрсә бар?<br>-Туп (курчак) бар.<br>-Нәрсә юк?<br>-Туп (курчак) юк.<br>“Бар”, “Юк” сүзләрен кулланып “Гаилә”, “Яшелчә” “Уенчыклар”<br>темаларын кабатлау.<br>Диалогларны кабатлау.<br>“Кибетле” уеннары. | Аудиоязма №50-60<br><br><br>Сюжет:<br>1. “Туган көн”<br>2. ”Кем нәрсә ярата?” |
| **БӘЙРӘМ “САБАНТУЙ”- 3 СӘГАТЬ (58-60)** | | |
| | Ел дәвамында өйрәнелгән сүзләр, сөйләм үрнәге кулланыла.<br>“Гаилә”, “Яшелчә”, “Уенчыклар” темаларын кабатлау.<br>“Кибетле” уеннары. | Аудиоязма №61-63<br><br>Сюжет:<br>1.“Сабантуй бәйрәме” |

**МӘКТӘПКӘ ӘЗЕРЛЕК ТӨРКЕМЕ «БЕЗ ИНДЕ ХӘЗЕР ЗУРЛАР – МӘКТӘПКӘ ИЛТӘ ЮЛЛАР» ПРОЕКТЫ БУЕНЧА ТЕМАТИК ПЛАН**

| АКТИВ СҮЗЛӘР | СӨЙЛӘМ ҮРНӘГЕ | АУДИОЯЗМА<br>ЭШ ДӘФТӘРЕ<br>АНИМАЦИОН СЮЖЕТ |
|---|---|---|
| син кем | | Аудиоязма №1 - 2 |
| хәерле көн | -Хәерле көн, Оля (Коля). | Аудиоязма №3 - 5 |
| | -Хәерле көн, әни (әти, бабай, әби). | Сюжет: “Мияу адашкан” |
| тычкан | | Аудиоязма №6 |
| | | Аудиоязма №7 - 8 |
| бу кем? | | Сюжет:”Аю баласы дөнья белән таныша” |
| бу нәрсә? | | Аудиоязма №9 - 10 |
| | | Аудиоязма №11 |
| нишли? | -Песи нишли? | |
| йоклый | -Песи йоклый. | Сюжет: “Батыр Мияу һәм куркак Куянкай” |
| утыра | | Аудиоязма №12 |
| | -Әни нишли? | Аудиоязма №13 - 14 |
| | -Әни утыра. | |
| | | Мультфильм: |
| ашый | -Коля нишли? | “Тату гаилә” |
| эчә | -Коля ашый (эчә). | Аудиоязма №15 |
| нишлисең? | -Мияу, нишлисең? | |
| ашыйм | -Ашыйм. | Аудиоязма №16 - 18 |
| эчәм | -Акбай, нишлисең? | Мультфильм: “Юмарт аю” |
| | -Эчәм. | |
| уйный | | |
| уйныйм | -Оля (Коля), нишлисең? | |
| утырам | -Уйныйм. | Аудиоязма №19 |
| барам | -Кая барасың? | |
| кая барасың? | -Кафега барам. | |

| | | |
|---|---|---|
| син нишлисең? | -Син нишлисең?<br>-Мин бәрәңге ашыйм (чәй эчәм, уйныйм, барам, утырам, йоклый) | Аудиоязма №20 |
| сикер-сикерәм | Туп, туп<br>Матур туп.<br>Сикер-сикер,<br>Матур туп. | Мультфильм: “Кафега барабыз”<br><br>Аудиоязма №21-23 |
| сикерә<br>йөгерә<br>төлке | Куян сикерә (йөгерә).<br>Туп сикерә.<br>Песи сикерә (йөгерә).<br>Төлке сикерә (йөгерә). | Мультфильм:<br>“Урманда күңелле уеннар”<br><br>Аудиоязма №24 |
| йөгер-йөгерәм | -Йөгер! Син нишлисең?<br>-Мин йөгерәм. | Аудиоязма №25-28<br><br>Мультфильм:<br>“Көчлеләр, кыюлар, җитезләр” |
| чәк-чәк<br>өчпочмак | -Мин чәк-чәк ашыйм.<br>-Мин өчпочмак ашыйм. | Аудиоязма №29-30 |
| яшь | -Сиңа ничә яшь?<br>-6 яшь. | Сюжет:<br>“Җәнлекләр спорт бәйрәмендә” |
| бүре<br>керпе | -Мин бүре. Мин зур, матур, чиста. | Аудиоязма №31-32 |
| тавык<br>әтәч | Әтәч зур, матур<br>Тавык кечкенә, матур | Аудиоязма №33-34<br>Сюжет:“Циркта” |
| үрдәк | -Син кем?<br>-Мин үрдәк. | Аудиоязма №35 - 36<br><br>Аудиоязма №37 - 38 |
| чана<br>шуа | Куян чана шуа. | Сюжет:“Шаян кошлар” |
| шуам | Мин чана шуам. | Аудиоязма №39 – 40 |

| | | |
|---|---|---|
| бие<br>бии<br>биим | -Аю, әйдә, бие! | Аудиоязма №41<br>Сюжет:<br>“Урманда зур концерт” |
| | | Аудиоязма №42 - 44 |
| ак<br>кара | -Оля кызыл шар ярата?<br>-Юк.<br>-Оля яшел шар ярата?<br>-Әйе, мин яшел шар яратам. | Аудиоязма №45 - 46<br><br>Сюжет: “Акбай туган көнгә барырга җыена” |
| җырла-җырлыйм | -Син нишлисең?<br>-Мин җырлыйм. | Аудиоязма №47 |
| | | Аудиоязма №45, 48 – 49 |
| зур рәхмәт | җырлыйбыз<br>зур рәхмәт | Сюжет:<br>“Мияуның туган көне” |
| китап укый | Кыз китап укый. | Аудиоязма №50 |
| рәсем ясыйм | рәсем ясыйм-алма ясыйм<br>мәктәп | Аудиоязма №51 - 53 |
| укыйм<br>дәфтәр | -Кем укый.<br>-Мин укыйм. | Сюжет:<br>“Урман китапханәсендә” |
| | бик тәмле | Аудиоязма №54 - 60 |
| | Терем-терем, теремкәй,<br>Зур түгел, кечкенә.<br>Теремкәйдә тычкан яши.<br>Теремкәйдә куян яши.<br>Теремкәйдә бүре яши.<br>Теремкәйдә төлке яши.<br>Теремкәйдә аю яши.<br>Алар бик дус. | Сюжет “Уйный-уйный укыйбыз”<br><br>Аудиоязма №61-63<br><br>Сюжет: “Урман мәктәбендә”<br><br>Аудиоязма №64<br>Сюжет: “Теремкәй” |
| | -Кәҗә кая?<br>-Әнә, кәҗә кәбестә ашый. Кәҗә кәбестә ярата. | Аудиоязма №65-66 |

| | | |
|---|---|---|
| | -Мин ипи яратам. Песи, син нәрсә яратасың?<br>-Мин сөт яратам. Сөт тәмле.<br><br>-Мә, кәҗә, ботка аша.<br>-Юк, кәбестә яратам. Кәбестә тәмле. | Сюжет: “Кем нәрсә ярата?”<br><br>Аудиоязма №67 - 71 |

**Ата- аналар белән эш**

- Ата – аналар җыелышында чыгышлар ясау.
- Консультацияләр үткәрү.
- Ачык ишекләр көне үткәрү.
- Балалар бакчасының сайтында информацияләрне яңартып тору.
- “Татарча сөйләшәбез” – “Говорим по – татарски” папкаларындагы информацияләрне яңартып тору.
- Индивидуаль консультацияләр бирү, әңгәмәләр үткәрү.
- Ата- аналарның, балаларның рәсемнәре күргәзмәсе үткәрү.

**Педагогик коллектив белән эш**

- Педагогик киңәшмәләрдә чыгышлар ясау.
- Консультацияләр бирү.
- Төркем тәрбиячеләре һәм белгечләр белән берлектә бәйгеләр үткәрү.

**Мәктәп белән бәйләнеш**

- Мәктәп һәм бакча  балалары белән уртак бәйрәмнәр үткәрү.
- Ата- аналар җыелышларына гимназия һәм мәктәп укытучыларын чакыру.
- Үзара эшчәнлек һәм дәресләр карау.

**Коррекция эше**

**«Минем өем» проекты буенча коррекция эше (Приложение)**

| **Үткәрү вакыты** | **№** | **Сораулар, биремнәр** | **Уеннар, күнегүләр, биремнәр** | **Төркем №** | **Баланың исеме фамилиясе** |
|---|---|---|---|---|---|
| Октябрь | 1. | “Минем өем” проекты буенча өйрәнгән лексиканы сөйләмдә куллану.<br>Бу кем? Бу нәрсә? сорауларына җавап бирү. | 1.Дидактик уен “Матур өйдә кем яши?”<br>2.Дидактик уен “Кем юк” (әйе – юк).<br>3.Дид.уен “Исемен әйтсәң бирәм” (гаилә әгъзалары, уенчыклар). | | |
| Ноябрь | 2. | Ягымлы сүзләр куллану (“Исәнме”, “Исәнмесез” , “Сау бул”, “Сау булыгыз”, “Рәхмәт”) | 1.Ситуатив күнегү “Куян аюга кунакка килә”.<br>2. Ситуатив күнегү "Кунак сыйлау".<br>3. Ситуатив күнегү "Дустыңны сыйла". | | |
| Декабрь<br>Январь | 3. | Боерыкны бирә белү<br>(кил, утыр, йокла, уйна, ю, аша, эч) | 1.Дид.уен: “Командир”.<br>2.Дид.уен «Мин әйтәм – син эшлә»<br>3. «Шаян уенчыклар» | | |
| Февраль<br>Март | 4. | Тирә - юньдәге предметларның сыйфатын, күләмен белдерә торган сүзләрне аңлап сөйләмдә куллану. | 1.Дид. уен “Бу нәрсә, ничә?”.<br>2.Уен ситуациясе: “Курчакка бүләк”(зур – кечкенә)<br>3.Дид.уен “Дөрес сана”. | | |
| Март<br>Апрель | 5. | Аралаша белү (ягымлы сүзләр әйтү, чакыру, сыйлау, сорап алу, тәкъдим итү, инкарь итү,раслау) | 1.Уен ситуациясе “Әйдә, танышыйк”.<br>2.Уен ситуациясе “Кунак каршылау”.<br>3.Уен ситуациясе “Кунак сыйлау”.<br>4.”Уенчык сорап ал”. | | |
| Май | | Татар телен үзләштерү дәрәҗәләрен билгеләү | | | |

**“Уйный-уйный үсәбез”проекты буенча коррекция эше**

| **Үткәрү вакыты** | **№** | **Сораулар, биремнәр** | **Уеннар, күнегүләр, биремнәр** | **Төркем №** | **Баланың исеме фамилиясе** |
|---|---|---|---|---|---|

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| Октябрь | 1. | “Уйный-уйный үсәбез” проекты буенча өйрәнгән лексиканы сөйләмдә куллану. Бу кем? Бу нәрсә? Нинди? Ничә? сорауларына җавап бирү. | 1.Дидактик уен “Бу нәрсә?”<br>2.Дидактик уен “Бу кем?”<br>3.Дидактик уен “Нинди? Ничә?”<br>4.Дидактик уен “Дөресен әйт”<br>5.Дидактик уен “Кем юк”. | | |
| Ноябрь | 2. | Ягымлы сүзләр куллану (“Исәнме”, “Исәнмесез”, “Сау бул”, “Сау булыгыз”, “Рәхмәт”, “Хәерле көн”,“Хәлләр ничек?”, “Әйбәт”). | 1.Ситуатив күнегү: “Яшелчәләр кибете”.<br>2. Ситуатив күнегү: «Телефоннан сөйләшү».<br>3.Уен ситуациясе "Дустыңны сыйла". | | |
| Декабрь<br>Январь | 3. | “Төсләр дөньясында”<br><br>Боерыкны бирә белү<br>(кил монда, утыр, сикер, уйна, ю, аша, эч, ки, сал, йокла) | 1. «Мияу-мияу нинди?»<br>2.Дид.уен «Командир».<br>3.Дид.уен «Мин әйтәм – син эшлә»<br>4. «Шаян уенчыклар» | | |
| Февраль<br>Март | 4. | Уен ситуацияләрендә үзлектән сорау куя белү. Киемнәрне, савыт-сабаларны, йорт җиһазларын ныгыту (Нәрсә кирәк? Нинди? Ничә? Син кем? Бу кем? Бу нәрсә?) | 1.Сюжетлы-рольле уен “Киемнәр кибете”<br>2.С/рольле уен “Савыт-саба кибете”.<br>С/рольле уен “Супермаркет”<br>3.Сюжетлы-рольле уен: «Туган көн».<br>Дид.уен «Парын тап» (төсләр) | | |
| Март<br>Апрель | 5. | Аралаша белү (ягымлы сүзләр әйтү, чакыру, сыйлау, сорап алу, тәкъдим итү, инкарь итү, раслау). | 1.Уен ситуациясе “Таныш булыйк”.<br>2.Уен ситуациясе “Кәрзиндә нәрсә бар”.<br>3.Уен ситуациясе “Куяннарга киенергә булыш”.<br>4.Уен ситуациясе “Аюлар яңа өйгә күчә, булыш”<br>5. Уен ситуациясе «Савыт-сабалар бүләк итәбез». | | |
| Май | | Татар телен үзләштерү дәрәҗәләрен билгеләү. | | | |

**“Без инде хәзер зурлар, мәктәпкә илтә юллар” проекты буенча коррекция эше**

| Үткәрү вакыты | № | Сораулар, биремнәр | Уеннар, күнегүләр, биремнәр | Төркем № | Баланың исеме фамилиясе |
|---|---|---|---|---|---|
| Октябрь | 1. | “Без инде хәзер зурлар, мәктәпкә илтә юллар” проекты буенча өйрәнгән лексиканы сөйләмдә куллану. Бу кем? Бу нәрсә? сорауларына җавап бирү. | 1.Дидактик уен “Бу нәрсә?”<br>2.Дидактик уен “Бу кем?”<br>3.Дидактик уен “Нинди? Ничә?”<br>4.Дидактик уен “Дөресен әйт”<br>5.Дидактик уен “Кем юк”. | | |
| Ноябрь | 2. | Ягымлы сүзләр куллану (“Исәнме”, “Исәнмесез”, “Сау бул”, “Сау булыгыз”, “Рәхмәт”, “Зур рәхмәт”, “Хәерле көн”,“Хәлләр ничек?”, “Әйбәт”) | 1.Ситуатив күнегү “Куян аюга кунакка килә”.<br>2. Ситуатив күнегү: «Телефоннан сөйләшү».<br>3.Уен ситуация "Дустыңны сыйла". | | |
| Декабрь Январь | 3. | Боерыкны бирә белү (кил, утыр, сикер, уйна, ю, аша, эч, ки, сал, бие, җырла, йөгер, йокла) | 1.Дид.уен “Командир”.<br>2.Дид.уен «Мин әйтәм – син эшлә»<br>3. «Шаян уенчыклар» | | |
| Февраль Март | 4. | Уен ситуацияләрендә үзлектән сорау куя белү. (Нәрсә кирәк? Нинди? Ничә? Син кем? Бу кем? Бу нәрсә? Нишли? Ничә яшь? (Сиңа ничә яшь?) Нишлисең? Син нишлисең?) Кая барасың?) | 1.Сюжетлы-рольле уен “Кибет”<br>2.Дидактик уен “Нинди?”.<br>3.Дидактик уен “Ничә?”.<br>4.Уен ситуация: «Кая барасың?”<br>5.Сюжетлы-рольле уен: “Туган көн”.<br>6. Дид.уеннар:<br>а)“Бу кем? Нишли?”<br>б) “Дөрес сана”<br>в “Мияу-Мияу нинди?<br>7. “Курчакка бүләк” (зур – кечкенә) | | |
| Март Апрель | 5. | Аралаша белү (ягымлы сүзләр әйтү, чакыру, сыйлау, сорап алу, тәкъдим итү, инкарь итү, раслау) | 1.Уен ситуациясе “Таныш булыйк”.<br>2.Уен ситуациясе “Портфельдә нәрсә бар?”.<br>3.Уен ситуациясе “Портфельдә нәрсә юк?”.<br>4.Уен ситуациясе “Теремкәйдә кем яши?” | | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | 5. Уен ситуациясе “Урман мәктәбендә” | | |
| Май | | Татар телен үзләштерү дәрәҗәләрен билгеләү. | | | |

**III НЧЕ БҮЛЕК. Оештыру**

**Материаль - техник яктан тәэмин ителеш**

| | | |
|---|---|---|
| Татар теле кабинеты | Белем бирү эшчәнлеге, индивидуаль, коррекцион эш, ата-аналар, педагоглар өчен консультацияләр, ачык эшчәнлекләр . | Зурлар һәм балалар өчен өстәлләр, урындыклар, компьютер, принтер, ноутбук, уенчыклар, дидактик, интерактив уеннар, балалар әдәбияты, тематик папкалар, альбомнар, укыту - методик комплект (демонстрацион, таратма материал, аудио, видео дисклар, маскалар, театрларның төрле төрләре),ТР һәм РФ символикасы. |

**Программалы - методик яктан тәэмин ителеш**

Зарипова З.М., Кидрячева Р. Г. Балалар бакчасында рус телле балаларга татар теле өйрәтү программасы. «Идел-Пресс», 2013.
Кидрячева Р.Г.  “Татарча сөйләшәбез”. 4-5 яшьлек балаларны татар теленә өйрәтү буенча методик ярдәмлек, «Хәтер», 2011.
Кидрячева Р.Г.  “Татарча сөйләшәбез”. 5-6 яшьлек балаларны татар теленә өйрәтү буенча методик ярдәмлек, «Хәтер», 2012.
Кидрячева Р.Г.  “Татарча сөйләшәбез”. 6-7 яшьлек балаларны татар теленә өйрәтү буенча методик ярдәмлек, «Татарстан китап нәшрияты», 2012.

**Тавышлы күрсәтмәлелек**

Кидрячева Р.Г.   “Минем өем” проеты буенча 4-5 яшьлек балалар өчен укыту-методик комплектына аудиоязмалар. “Аксу” компаниясе, 2012.
Кидрячева Р.Г.   “Уйный- уйный үсәбез” проекты буенча 5-6 яшьлек балалар өчен укыту-методик комплектына аудиоязмалар. “Аксу” компаниясе, 2012.
Кидрячева Р.Г.   “Без инде хәзер зурлар, мәктәпкә илтә юллар”, проекты буенча 6-7 яшьлек балалар өчен укыту-методик комплектына аудиоязмалар. “Аксу” компаниясе, 2012.
Кидрячева Р.Г.  “Минем өем” проекты буенча 4-5 яшьлек балалар өчен анимацион сюжетлар. “Аксу” компаниясе, 2012.
Кидрячева Р.Г.  “Уйный- уйный үсәбез” проекты буенча 5-6 яшьлек балалар өчен анимацион сюжетлар. “Аксу” компаниясе, 2012.

**Күрсәтмә, таратма материаллар,**
**театр эшчәнлеге өчен атрибутлар.**

**“Минем өем” проекты буенча 4-5 яшьлек балалар өчен**

| | | |
|---|---|---|
| 1.А4 форматында | «Минем гаилә»<br>Бабай, әби, әти, әни, малай, кыз. | Һәрберсе<br>1 данә |

| | | |
|---|---|---|
| күрсәтмә рәсемнәр. | | |
| | Зур уенчыклар: курчак, куян, аю, туп, песи, эт, машина.<br>Кечкенә уенчыклар: курчак, куян, аю, туп, песи, эт, машина. | Һәрберсе<br>1 данә |
| | «Ашамлыклар»<br>Ипи, алма, чәй, сөт. | Һәрберсе<br>1 данә |
| | «Уенчыклар»<br>Курчак, куян, аю, туп, песи, эт, машина.<br>курчак, куян, аю, туп, песи, эт, машина – пычрак уенчыклар. | Һәрберсе<br>1 данә |
| | Сюжетлы рәсемнәр: «Куян өйгә керә, өйдә аю утыра». «Куян өйдән чыга, саубуллаша». | Һәрберсе<br>1 данә |
| | Рәсемнәр: 1 куян, 2 куян, 3 куян, 4 куян, 5 куян;<br>1 аю, 2 аю, 3 аю, 4 аю, 5 аю;<br>1 курчак, 2 курчак, 3 курчак, 4 курчак, 5 курчак;<br>1 туп, 2 туп, 3 туп, 4 туп, 5 туп;<br>1 машина, 2 машина, 3 машина, 4 машина, 5 машина;<br>1 песи, 2 песи, 3 песи, 4 песи, 5 песи;<br>1 эт, 2 эт, 3 эт, 4 эт, 5 эт. | Һәрберсе<br>1 данә |
| 2.А3 форматында өй рәсеме. | Өй макеты | 1 данә |
| 3. А 5 форматында таратма рәсемнәр. | «Минем гаилә»<br>Бабай, әби, әти, әни, малай, кыз. | Һәрберсе 15 данә |
| | «Ашамлыклар»<br>Ипи, алма, чәй, сөт. | Һәрберсе 15 данә |
| | «Уенчыклар»<br>Курчак, куян, аю, туп, песи, эт, машина. | Һәрберсе 15 данә |
| 4. Театр эшчәнлеге өчен атрибутлар. | Битлекләр: бабай, әби, әти, әни, малай, кыз, куян, аю, песи, эт. | Һәрберсе 15 данә |
| Бармак уеннары өчен | бабай, әби, әти, әни, малай, кыз, эт Акбай, песи Мияу, аю, куян. | Һәрберсе 15 данә |

| | | |
|---|---|---|
| атрибутлар | | |

**“Уйный-уйный үсәбез” проекты буенча 5-6 яшьлек балалар өчен**

| | | |
|---|---|---|
| 1. Күрсәтмә рәсемнәр. | «Минем гаилә»<br>Малай, кыз рәсемнәр («Курчакны киендер» уены. Кыз, малай өчен киемнәр: күлмәк (кызларныкы, малайларныкы), футболка, шорты, чалбар, сарафан - (зәңгәр, кызыл, сары, яшел төсләрдә). | Һәрберсе<br>1 данә |
| | «Уенчыклар»<br>Зур уенчыклар: курчак, туп, машина - (зәңгәр, кызыл, сары, яшел төсләрдә).<br>Кечкенә уенчыклар: курчак, туп, машина - (зәңгәр, кызыл, сары, яшел төсләрдә). | Һәрберсе<br>1 данә |
| | «Ашамлыклар»<br>Аш, ботка, чәк-чәк, конфет, сок. | Һәрберсе<br>1 данә |
| | «Савыт-саба»<br>Зур рәсемнәр: кашык, тәлинкә, чынаяк - (зәңгәр, кызыл, сары, яшел төсләрдә).<br>Кечкенә рәсемнәр: кашык, тәлинкә, чынаяк - (зәңгәр, кызыл, сары, яшел төсләрдә). | Һәрберсе 1 данә |
| | «Җиләк-җимешләр»<br>Зур рәсемнәр: яшел алма, сары, кызыл, банан, апельсин, виноград, груша.<br>Кечкенә рәсемнәр: яшел алма, сары, кызыл, банан, апельсин, виноград, груша. | Һәрберсе<br>1 данә |
| | «Яшелчәләр»<br>Зур рәсемнәр: кишер, бәрәңге, суган, кыяр, кәбестә.<br>Кечкенә рәсемнәр: кишер, бәрәңге, суган, кыяр, кәбестә. | Һәрберсе<br>1 данә |
| | «Киемнәр»<br>Зур рәсемнәр: күлмәк (кызларныкы, малайларныкы), чалбар - (зәңгәр, кызыл, сары, яшел төсләрдә).<br>Кечкенә рәсемнәр: күлмәк (кызларныкы, малайларныкы), чалбар - (зәңгәр, кызыл, сары, яшел төсләрдә). | Һәрберсе<br>1 данә |
| | «Өй җиһазлары»<br>Зур рәсемнәр: карават, урындык, өстәл - (зәңгәр, кызыл, сары, яшел төсләрдә).<br>Кечкенә рәсемнәр: карават, урындык, өстәл - (зәңгәр, кызыл, сары, яшел төсләрдә). | Һәрберсе<br>1 данә |
| | «Төсләр»<br>Палитра: зәңгәр, кызыл, сары, яшел. | Һәрберсе<br>1 данә |
| | «Саннар»10) | Һәрберсе<br>1 данә |
| 2. Таратма рәсемнәр. | «Минем гаилә»<br>Малай, кыз рәсемнәре: («Курчакны киендер» уены. Кыз, малай өчен киемнәр: күлмәк (кызларныкы, малайларныкы), футболка, шорты, чалбар, сарафан - (зәңгәр, кызыл, сары, яшел төсләрдә). | Һәрберсе 15 данә |
| | «Уенчыклар» | Һәрберсе 15 данә |

| | | |
|---|---|---|
| | Зур уенчыклар: курчак, туп, машина - (зәңгәр, кызыл, сары, яшел төсләрдә).<br>Кечкенә уенчыклар: курчак, туп, машина - (зәңгәр, кызыл, сары, яшел төсләрдә). | |
| | «Ашамлыклар»<br>Аш, ботка, чәк-чәк, конфет, сок. | Һәрберсе 15 данә |
| | «Савыт-саба»<br>Зур рәсемнәр: кашык, тәлинкә, чынаяк - (зәңгәр, кызыл, сары, яшел төсләрдә).<br>Кечкенә рәсемнәр: кашык, тәлинкә, чынаяк - (зәңгәр, кызыл, сары, яшел төсләрдә). | Һәрберсе 15 данә |
| | «Җиләк-җимешләр»<br>Зур рәсемнәр: яшел алма, сары, кызыл, банан, апельсин, виноград, груша.<br>Кечкенә рәсемнәр: яшел алма, сары, кызыл, банан, апельсин, виноград, груша. | Һәрберсе 15 данә |
| | «Яшелчәләр»<br>Зур рәсемнәр: кишер, бәрәңге, суган, кыяр, кәбестә.<br>Кечкенә рәсемнәр: кишер, бәрәңге, суган, кыяр, кәбестә. | Һәрберсе 15 данә |
| | «Киемнәр»<br>Зур рәсемнәр: күлмәк (кызларныкы, малайларныкы), чалбар - (зәңгәр, кызыл, сары, яшел төсләрдә).<br>Кечкенә рәсемнәр: күлмәк (кызларныкы, малайларныкы), чалбар - (зәңгәр, кызыл, сары, яшел төсләрдә). | Һәрберсе 15 данә |
| | «Өй җиһазлары»<br>Зур рәсемнәр: карават, урындык, өстәл - (зәңгәр, кызыл, сары, яшел төсләрдә).<br>Кечкенә рәсемнәр: кровать, стул, стол - (зәңгәр, кызыл, сары, яшел төсләрдә). | Һәрберсе 15 данә |
| 3.Буяу өчен график рәсемнәр | 1 аю, 2 куян, 2 машина, 2 курчак, 3 бәрәңге, 4 кәбестә, 4 курчак, 5 песи, 6 алма, 6 кыяр, 7 туп, 7 бәрәңге, 8 кишер, 9 суган, 10 эт. | Һәрберсе 15 данә |
| 4.Театр эшчәнлеге өчен атрибутлар. | Битлекләр: кишер, суган, кыяр, бәрәңге, кәбестә, алма. | Һәрберсе 15 данә |
| 5. Театр эшчәнлеге өчен атрибут лар. | 1.Өстәл театры өчен атрибутлар (конус формасында): «Өч аю»: əти аю, әни аю, бала аю.<br>2. Өстәл театры өчен атрибутлар (конус формасында): «Кем нәрсә ярата»: песи, эт, аю, куян, кәҗә, әтәч.<br>өстәл (зур, уртача зурлыкта, кечкенә);<br>урындык (зур, уртача зурлыкта, кечкенә);<br>карават (зур, уртача зурлыкта, кечкенә). | Һәрберсе<br>1 данә<br><br>Һәрберсе<br>1 данә |

**“Без инде хәзер зурлар-мәктәпкә илтә юллар” проекты буенча**
**6-7 яшьлек балалар өчен**

| | | |
|---|---|---|
| 1.А 4 форматын | Үрдәк, бүре, әтәч, тавык, зур тычкан, кечкенә тычкан, китап, альбом, клей, линейка, ручка, карандаш, пенал, дәфтәр, кофе, пицца, бәрәңге фри, өчпочмак. | Һәрберсе<br>1 данә |

| | | |
|---|---|---|
| а күрсәтмә рәсемнәр. | | |
| | Шарлар - (зәңгәр, кызыл, сары, яшел төсләрдә). | Һәрберсе 1 данә |
| | Сюжетлы рәсемнәр: куян чана шуа, аю чана шуа, бүре чана шуа, төлке чана шуа, үрдәк чана шуа, тавык чана шуа, тычкан чана шуа, төлке бии, керпе йоклый, бүре йөгерә, төлке утыра, керпе уйный, аю йоклый, песи сөт эчә, эт ашый, төлке йөгерә, куян сикерә, тычкан ашый, әтәч җырлый, кыз кул юа, малай китап укый, кыз китап укый, төлке китап укый, куян китап укый, әни кул юа, әти йоклый, малай утыра, кыз бит юа, әби утыра, бабй йоклый. | Һәрберсе 1 данә |
| 2. А 5 форматында таратма рәсемнәр. | Үрдәк, бүре, әтәч, тавык, зур тычкан, кечкенә тычкан, китап, альбом, клей, линейка, ручка, карандаш, пенал, дәфтәр, кофе, пицца, бәрәңге фри, өчпочмак. | Һәрберсе 15 данә |
| | Шарлар - (зәңгәр, кызыл, сары, яшел төсләрдә). | Һәрберсе 15 данә |
| | Сюжетлы рәсемнәр: куян чана шуа, аю чана шуа, бүре чана шуа, төлке чана шуа, үрдәк чана шуа, тавык чана шуа, тычкан чана шуа, төлке бии, керпе йоклый, бүре йөгерә, төлке утыра, керпе уйный, аю йоклый, песи сөт эчә, эт ашый, төлке йөгерә, куян сикерә, тычкан ашый, әтәч җырлый, кыз кул юа, малай китап укый, кыз китап укый, төлке китап укый, куян китап укый, әни кул юа, әти йоклый, малай утыра, кыз бит юа, әби утыра, бабай йоклый. | Һәрберсе 15 данә |
| 8х10 форматында пиктограммалар | Бии, йоклый, утыра, ашый, эчә, уйный, сикерә, йөгерә, укый, рәсем ясый, җырлый, чана шуа, мин, кыз, малай, әби, бабай. | Һәрберсе 15 данә |
| 15х20 форматында пиктограммалар | Бии, йоклый, утыра, ашый, эчә, уйный, сикерә, йөгерә, укый, рәсем ясый, җырлый, чана шуа, мин, кыз, малай, әби, бабай, куян, төлке, песи, эт, аю, әтәч, тавык, үрдәк, керпе, тычкан. | Һәрберсе 1 данә |

**Әдәбият**


1.Зарипова З.М., Кидрячева Р.Г. Балалар бакчасында рус балаларына татар теле өйрәтү программасы. «Идел-Пресс», 2013.

2.Зарипова З.М., Кидрячева Р.Г. “Татарча сөйләшәбез”. 4-5 яшьлек балаларга татар теле өйрәтү буенча методик кулланма, «Хәтер», 2011

3.Зарипова З.М., Кидрячева Р.Г. “Татарча сөйләшәбез”. 5-6 яшьлек балаларга татар теле өйрәтү буенча методик кулланма, «Хәтер», 2012

4.Зарипова З.М., Кидрячева Р.Г. “Татарча сөйләшәбез”. 6-7 яшьлек балаларга татар теле өйрәтү буенча методик кулланма, «Татарстан китап нәшрияты», 2014.

5.Закирова К.В., Муртазина Л.Р. “Әй, уйныйбыз, уйныйбыз”.- Казан, 2013.

6.Зарипова З.М., Исаева Р.С. “Үстерешле уен”.- Казан, 2013.

7.К. В. Закирова К.В., Муртазина Л.Р. “Балачак – уйнап - көлеп үсәр чак”.- Казан, 2012.